**СОВЕТ**
**Красноборского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Красный Бор авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

02.12.2025 Красный Бор авылы № 5-1

"Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге Советының 2019 елның 26 ноябрендә кабул ителгән 53-1 номерлы «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Красный Бор авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәне раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында"

Россия Федерациясе Бюджет кодексына, 2025 елның 21 апрелендә кабул ителгән 84-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясенең аерым закон актлары кагыйдәләрен туктатып тору, Россия Федерациясенең аерым закон актлары кагыйдәләрен гамәлдән чыгару һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын 2025 елда башкару үзенчәлекләрен билгеләү турында»гы Федераль законның 14 һәм 15 нче маддәләренә үзгәрешләр кертү турында»гы Федераль законына, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе районы прокуратурасының 2025 елның 23 октябрендә кабул ителгән 02-08-01-2025/174 номерлы протестын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлеге Советының 2019 елның 26 ноябрендә кабул ителгән 53-1нче номерлы карарына, «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Красный Бор авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы кагыйдәләрне раслау турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:
   1.1. 30 нчы маддәнең 5 нче өлешендә «муниципаль-шәхси партнерлык килешүләре» сүзләреннән соң «публичный партнер түләве, капиталь грант күләмендә» сүзләрен өстәргә;
   1.2. 42 нче маддәгә тугызынчы пунктны түбәндәге эчтәлек белән өстәргә: «9. Суд актларын (кешеләргә китерелгән зыянны компенсацияләү

максатыннан чыгарылган суд актларыннан тыш) үтәү, аларны агымдагы финанс елында бюджет ассигнованиеләре бүлеп бирүне таләп итә, бюджет турындагы закон (карар) белән каралган ассигнованиеләр чикләрендә, суд акты белән билгеләнгән максатларга туры килгән чыгым маддәләре буенча башкарыла».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында, https://agryz.tatarstan.ru веб-адресы буенча интернет челтәрендә урнаштырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.
3. Хәзерге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Яковлева Е.А.